Республика Татарстан
Зеленодольский муниципальный район
**Исполнительный комитет Большеключинского сельского поселения**
Волостнова ул., 16а с.Б.Ключи, 422524

Татарстан Республикасы
Зеленодол муниципаль районы
**Зур Ключи авыл җирлеге башкарма комитеты**
Волостнова ур., 16а З.Ключи ав, 422524

ПОСТАНОВЛЕНИЕ с.Большие Ключи КАРАР

№ 20 26 июнь 2018 ел

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге
Башкарма комитетының «Зур Ключи авыл җирлегенең
азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты
көнкүреш калдыкларын чыгару турында»
2017 елның 20 ноябрендәге 48 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында» 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карары нигезендә, чисталыкны тәэмин итү, йогышлар таралуны булдырмау һәм экологик хәлне яхшырту максатларында,

**КАРАР:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авыл җирлеге Башкарма комитетының «Большие Ключи авыл җирлегенең азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында»2017 елның 20 ноябрендәге 48 номерлы карарына үзгәрешләр кертү:

1.1 пункт 1.2. яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Килешү төзегәндә каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү бәясен, контейнер мәйданчыкларын җыештыруны исәпкә алып, бер кешегә аена 58,5 сумнан да артмаска тиеш.;

1.2 пункт 1.3. яңа редакциядә бәян итәргә: «1.3. Теркәлгән гражданнар булмаган очракта, каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү бәясен, контейнер мәйданчыкларын җыештыруны исәпкә алып, йорт хуҗалыгыннан аена 58,5 сумнан да артык түгел».

2. Әлеге карар 2018 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга .http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук җирлекнең мәгълүмати стендларында).

**Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гатауллин**